**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Биккол авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«22» июль 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 22 июлендә тъбщндщге мәсьәлә буенча узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында халык җыены нәтиҗәләре турында 27.11.2021 ел, № 1 карарына

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында халык җыены карарына (27.11.2021 ел), аны киләсе редакциядә раслап:

«2022 елда үзара салым кертүгә Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- янгын сүндерү техникасын урнаштыру өчен торак булмаган бинаны капиталь ремонтлау;

- Биккол авылында юллар салу өчен вак таш сатып алу;

- Биккол торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кыш көне карап тоту» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 260 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 137 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 134 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 3 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрга.

Элегрәк расланган Халык Җыенына кертелгән сорауга үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында халык җыены нәтиҗәләре турында 27.11.2021 ел, № 1 карарына

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында халык җыены карарына (27.11.2021 ел), аны киләсе редакциядә расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- янгын сүндерү техникасын урнаштыру өчен торак булмаган бинаны капиталь ремонтлау;

- Биккол авылында юллар салу өчен вак таш сатып алу;

- Биккол торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кыш көне карап тоту» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х.Әхмәтшина

Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Әхмәтшина